ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__819__ «_12_»____07_______2016 ел

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга
социаль ярдәм чаралары бирү турында» Мамадыш муниципаль
районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның
18 сентябрендәге 1333 номерлы карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 12 апрелендәге 20-18/4912 номерлы хаты нигезендә, Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 18.09.2013 елның 18 сентябрендәге № 1333 карары белән расланган "Мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибендә" 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.6 п. өстәргә:
   "Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлекчәләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан алырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара мәгълүмати багланышларның региональ системаларын кулланып, эш бирүче (иминләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка түләүләр суммасы турында белешмәләр, компенсация билгеләү аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә мөрәҗәгать итүчегә билгеләнгән айга кадәрге соңгы 3 айда 12 айда башкарыла".
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П.Смирновага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Ш.М.Сабиров